МИНИСТЕРСТВО
СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА
И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ
ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

13.04.2016 Казан ш. № 73/2-пр

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2016 елның 28 апрелендә теркәлде, № 3345

“2016 елга Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан алына торган средстволар хисабына субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 15.01.2016 ел, №1/2-пр Татарстан республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына №1 кушымтага үзгәрешләр кертү хакында

“Үсемлекчелек өлкәсендә тәгаен чыгымга бәйле булмаган ярдәм күрсәтүгә һәм авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре өчен субсидияләр күләмнәрен арттыру максатыннан чыгып, Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында” 27 декабрь, 2012 ел, №1431 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарын үтәү йөзеннән, боерык бирәм:

1. “2016 елга Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан алына торган средстволар хисабына субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 15.01.2016 ел, №1/2-пр Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына №1 кушымтадагы 6 пунктка үзгәрешләр кертеп, аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре өчен чәчүлек мәйданының 1 гектарына субсидияләр күләме түбәндәге формула буенча исәпләнелә:

$V = П \times (200{,}0 + (3{,}5 \times У) + (62{,}7 \times И_{ппмр}))$,

биредә:

V – күчерү өчен субсидияләр күләме, сум.;

П – чәчүлек мәйданы - гектарда (2015 елга уңыш җыеп алу турында рәсми статистика хисабына нигез итеп алына торган, фактдагы чәчүлек

мәйданнары турында мәгълүмат белән расланган) (алга таба – урып җыю йомгаклары турында мәгълүмат);

200,0 – чәчүлек мәйданының гектарына минималь ставка, сумнарда;

3,5 – җитештерелә торган ашлык берәмлегенең 1 центнерына минималь ставка, сумнарда;

У – бу Тәртипкә №2 кушымтага туры китереп, күчерү коэффициентлары нигезендә исәпләнгән, урып-җыю йомгаклары турында мәгълүмат нигезендә, чәчүлек мәйданнарының бер гектарында җитештерелгән ашлык берәмлегенең центнерлардагы чагылышында авыл хуҗалыгы культураларының уртача уңышы;

62,7 – җирләрнең уңдырышлылыгы буенча чәчүлекләрнең бер гектарына уртача ставка, сумнарда;

$И_{ппмр}$ – “бу Тәртипкә №1 кушымта нигезендә, “Татарский” агрохимия хезмәте үзәге” федераль дәүләт бюджет учреждениесе һәм “Әлмәт” агрохимия хезмәте станциясе” федераль дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – агрохимия хезмәтләре) тарафыннан тапшырылган мәгълүматлар нигезендә билгеләнгән, Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча туфракның уңдырышлылыгының уртача индексы.”.

2. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары Н.Л.Титовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г.Әхмәтов